| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**25.11.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 4433** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы милкендәге арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы, 2008 елның 22 июлендәге «Дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм арендага алынган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 159-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы милкендәге арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган түләүне кичектереп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен биш ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел тәшкил итә.
2. Арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган арендаланучы күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләү тәртибен (берьюлы яисә кичектереп түләү), шулай ук әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә кичектереп түләү срогын сайлау хокукы кече яисә урта эшкуарлык субъектына карый.
3. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» һәм «Яшел Үзән» газеталарында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин